# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

«31» май, 2019 ел Яр Чаллы № 2039

Мәҗбүри һәм төзәтү эшләре рәвешендә хөкем ителгән затларга җәзаны үтәү өчен оешмалар, предприятиеләр һәм учреждениеләр исемлеген раслау турында

Россия Федерациясе Җинаять-башкарма кодексының 25 маддәсе, Россия Федерациясе Җинаять кодексының 49 маддәсе, «Башкару хезмәте турында» 2010 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ санлы Федераль законның 109.2 маддәсе 3 пункты 1 пунктчасы нигезендә, «Җәзалар үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе Җинаять-башкарма инспекциясе» федераль казна учреждениесе Тукай муниципальара филиалының 2018 елның 25 июнендәге 17/ТО/825/30-850 санлы хатын үтәү йөзеннән

## КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 16 июлендәге 3142 санлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
2. Мәҗбүри һәм төзәтү эшләре рәвешендә хөкем ителгән затларга җәзаны үтәү өчен оешмалар, предприятиеләр һәм учреждениеләр исемлеген расларга.
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.Г. Авзалов